ГЛАВА ПЕЧИЩИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ПЕЧИЩИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

02.05.2017 с. Печищи № 3

Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлегендә Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Печищи авыл җирлеге уставы белән,

Карар бирәм:

1. Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлегендә җирләрдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Билгеләргә:

- гавами тыңлаулар уздыру вакыты - 2017 елның 13 мае, 10.00 сәгатьтә Печищи авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында;

- фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр бирелә торган адрес, ачык тыңлауларда катнашу өчен чыгыш ясау хокукы белән гаризалар бирелә ала: Декабристлар ур., 35а йорт Печищи авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре Л.Д. Волковага эш көннәрендә - 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр;

- Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга заявкалар бирү срогы - 2017 елның 12 маена кадәр ( тел: 8(84379)2-29-44)

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге башлыгы А.С. Шамсутдинов